МӨҖӘҺИТ

# Батыр буласым килә

Балалар өчен шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М96

Рәссамы *Рөстәм Хәбибуллин*

**Мөҗәһит**

М96 Батыр буласым килә : балалар өчен шигырьләр / Мөҗәһит. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 71 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-01953-8

Балаларга аңлаешлы, җиңел тел белән язылган, кызыклы вакыйгаларны, күренешләрне үз эченә алган шигырьләр аша укучы серле табигать дөньясы, ел фасыллары белән таныша. Шигырь геройларына ияреп, балыкка йөри, җиләк җыя, бәбкә саклый... Шул рәвешле тирә-юньне танып белергә өйрәнә.

Китап мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01953-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Әхмәтҗанов М.З., 2010

## Шундый туган як

Җәйләр яшел,
Кышлар ак.
Бездә шундый
Туган як.

Көзен сары,
Алтындай.
Янып торган
Ялкындай.

Ә нинди соң
Гөлле яз?
Аңа бөтен
Төсләр хас.

## Кояш җәйгә хәл ала

Сез дә уйлый торгансыздыр,
Мин дә бик еш баш ватам.
Хәйләкәр дә соң бу Кояш,
Менә шуңа шаккатам.

Җәй җиттеме, баш очында
Йөзә ул, тирләп-пешеп.
Сусавын баса һәрвакыт,
Безнең инешкә төшеп.

Ә кышларын, салкын булгач,
Тунын киеп куя да
Кешеләргә озак итеп
Күренергә ояла.

Көзен сирпеп бер үтә дә
Йокысына тала ул.
Зинһар, уята күрмәгез,
Җәйгә дип хәл ала ул.

## Салкын керләр киптерә

Бик салкын көнне
Әни кер юды.
Керләрен тышка
Элде дә куйды.

– Ничек кипсен, – дим. –
Өйгә кертеп эл.
Әни елмая:
– Моннан соң син бел:

Юеш керләрне
Салкын тиз тешли.
Җил дә, кузгалып,
Үз эшен эшли.

Менә иртәнгә
Үзең күрерсең,
Кипкән керләрне
Алып керерсең.



## Сәбәбе нидә икән?

Чәйне мин үзем генә дә
Пешереп эчә беләм.
Тик нигәдер чәй икенче,
Тәмлерәк әни белән.

Җәен җиләккә барганда,
Әни булса янында,
Рәхәтлекнең чиге булмый
Табигать кочагында.

Әни урынны җәйдеме,
Керә тәмле төш кенә.
Шушы кызыклы хәлләрнең
Кем серенә төшенә?

## Кунаклар белән генә

Никтер, кунак чакыргач,
Өйгә ямь кереп китә.
Кунак көткән вакытлар
Шулкадәр озак үтә.

Югыйсә бит һәммәбез
Бик зарыгып көтәбез.
Капка һәм өй арасын
Таптап арып бетәбез.

Килмиләр дә килмиләр,
Әллә өйне белмиләр.
Койма башында утырдым,
Юк, һаман күренмиләр.

...Ай-яй безнең кунаклар
Бигрәк җитез икәннәр.
Мин коймадан төшкәнче,
Килгәннәр дә җиткәннәр.

Кунаклар бар чагында,
Әти дә көлеп тора,
Әни дә көлеп тора.
Кунаклар белән генә
Яшисе килеп тора.




## Их, кар яуса!

Их, кар яуса!..
Кар яусамы,
Чаңгыга чыгар идем.
Салкын булса да курыкмыйм,
Барыбер чыдар идем.

Салкын булса, шугалак та
Тиз(е)рәк катар иде.
Иптәш малайлар көн буе
Шар сугып ятар иде.

Их, кар яуса!..
Рәхәтләнеп,
Ак кардан йөрер идек.
Тирә-якны, ду китереп,
Шатлыкка төрер идек.

## Чаңгы шудым

Таудан чаңгы шуган идем,
Түзмәде – сынды шартлап.
Тауга шуып барган идем,
Кайттым чаңгымда атлап.



## Бүре бүрек

Урамнан горур атлап
Килә бер бүре бүрек.
Куян бүрек калтырый,
Шундый бүрекне күреп.
Төлке бүрек хәйләкәр,
Күзәтә читтә йөреп.
Җитмәсә, бер сәхнәгә
Менеп китте йөгереп.
Әй тотынды җырларга,
Әй тотынды биергә.
Бүре бүрек кул чаба,
Белми нәрсә дияргә.
Хәйләкәр төлке бүрек,
Сокланды халык, күреп.
Көнләште бүре бүрек.
Бәлки, китәр дә иде
Җир тишегенә кереп,
Бүрек кенә шул бүрек…









## Зоопарк ачтык без

Безнең өйдә зоопарк.
Әгәр ышанмасагыз,
Үзегез килеп карагыз
Йә культпоход ясагыз.

Әти мине җәйге чорга
Куйды директор итеп.
Вазифаларны санады,
Колакка киртеп-киртеп.

– Акбайны син каравылчы
Итеп тотарсың, – диде.
– Буш вакытта бакчабызда
Чүп-чар утарсың, – диде.

– Булды, – дидем, – аңлашылды.
Башка фәрман көтмәдем.
Тавыкларны күзәтүне
Кикринурга йөкләдем.



Әтәчебез шатлыгыннан
Быргысында уйнады.
Таралышкан тавыкларның
Барсын бергә җыйнады.

Нотык тоткан булды үзе,
Бурычлар куя-куя.
– Көн саен сез йомырканы
Салыгыз, – ди, – бер оя!



Берегез дә югалмагыз,
Бакчага да кермәгез.
Командирга сүз тидереп,
Түтәл таптап йөрмәгез.

Аннан соң мин әмеремне
Ата казга җиткердем.
Билгеле инде, аны да
Түрә-башлык иттердем.

– Үрдәкләр дә синең кул
Астында булсын, – дидем.
– Барыгыз, күлгә китегез,
Юлыгыз уңсын, – дидем.



Ата казга иярделәр
Үрдәкләр дә, казлар да.
Кәҗә, сакалын селкетеп,
Карап калды абзарда.



Аңа бүген хөкем шундый,
Тәртипсез булган өчен;
Көтүдән качып, бакчада
Караклык кылган өчен.



Читлектә утыра куян.
Аннан миңа ни зыян?
Ашарына бакчабыздан
Үләннәр утап куям.

Ә Мыраубикә кояшта
Һаман йокы симертә.
– Миңа тычканнар тотарга
Әле иртә, – ди, – иртә.

Үзенең яшел күзләре
Уйнаклап кына тора.
Мөгаен, теге чыпчыкны
Тотарга ният кора.

Юк инде, юк, пескәем,
Өметләнмә чыпчыкка.
Акбайдан үрнәк ал бераз,
Ул бит тими кошчыкка.

Хәзер кош-корт, хайваннарның
Телләрен бик шәп беләм.
Алар мине якын итә,
Сөйләшә минем белән.

Чын зоопарк ачтык быел
Акбай белән икебез.
Сезне кунакка көтәбез,
Безгә рәхим итегез!



## Аллы-гөлле яз килде

Ялындырып торды да
Кинәт кенә килде яз.
Әллә безнең теләкне,
Яратканны белде яз.

Яланбашка калдырды,
Итекләрне салдырды.
«Минем турда җыр яз», – дип,
Кулга каләм алдырды.

Язбикәбез терелде,
Ямь-яшелгә төренде.
Аллы-гөлле көянтәсе
Баш очында күренде.

# Мавыктыргыч галәм

Аяз төндә күк йөзендә
Йолдызлар җемелдәшә.
Әйтерсең лә үз телендә
Алар безгә эндәшә.

Юк, ышанмыйм, ә шулай да
Йолдызларның сере бар.
Чөнки күктә бит аларның
Меңәрләгән төре бар.

Кайсылары хәрәкәттә:
Йә кабына, йә сүнә.
Сәлам җибәрәсем килә
Аларның һәрберсенә.

Аяз төндә күк йөзенә
Карыйм да уйга калам.
Нинди матур һәм сихри,
Мавыктыргыч бу галәм.



## Атлар

Болын тулып колын чаба,
Юыртып йөри тайлар.
Аргамакларга атланып
Куышалар малайлар.

Айгырлар кешни араннан –
Сабантуй якынлаша.
Җиңүгә өмет итәләр
Чаптар, бия, алаша.

Бәйгеләрдә юртак була
Асыллары атларның.
Елкылар искә төшерә
Юрга булган чакларын.

Байтал диеп тә атыйлар
Атларның кайберләрен.
Хәзер менә үзең санап
Кара атның төрләрен.

## Тәрәзле телефон

Никтер кесә телефонын
Кәрәзле дип атыйлар.
Шул кәрәзле телефонны
Бөтен җирдә мактыйлар.

Нинди кәрәз булсын анда?
Ул чынлыкта – тәрәзле.
Менә шул тәрәзәсендә
Сурәтләр, сүзләр әзме?

...Телефонның тәрәзәсе
Бер балкый да бер сүнә.
Сөенеч-хәбәр җибәрдем
Дусларымның берсенә.

## Усал шул минем апам

Апамның бар белгәне:
«Тәртипле тот бүлмәне.
Синнән соң өйгә керсәң,
Була батып үлмәле.

Уйнап гомер уздырма,
Тузанны да туздырма,
Иманың укытырмын,
Минем канны кыздырма!

Каралганмы дәресең?
Әйт син миңа дөресен.
«2» ле алып кара,
Күрмәгәнең күрерсең...»

Апа, әни юк чакта,
Тәртипне каты тота.
Холкы начар шул аның,
Шуңа бераз куркыта.





## «2» ле алгач

Сорап-сорап та белмәгәч,
Апа куйды «2» ле.
«2» ле алдым диеп, мин
Елап тормам бит инде.

Күзгә яшь чыгармасам да,
Ул эчне тырный икән.
Йөргәндә дә, ятканда да
Онтылып тормый икән.

«2» леләр, урап алып,
Төшләремә керделәр.
Чаян кебек чага-чага,
Кот очырып йөрделәр.

Шул «2» ле булмаганда,
Рәхәт иде үземә.
Хәзер инде күренергә
Оят кеше күзенә.

## Рәхмәт рәхәт икән

Тәрәз буена утырып,
Әбием нидер текте.
Җебе чыккач, энәсенә
Кертә алмый интекте.

Йөгереп кенә килдем дә
Мин җебен бирдем саплап.
Әбинең күңеле булды:
Рәхмәт әйтте кочаклап.

«Рәхмәт» сүзен ишетүе
Күңелле, рәхәт икән.
Бер серле сүз белдем әле:
Гап-гади «рәхмәт» икән.





## Һич төшенмим

Тыңлаусыз да соң бу әни,
Уздыра этине дә.
Төпчек улым дип тә тормый,
Санга сукмый мине дә.

Әйттең исә, гел киресен
Эшләп кенә торалар.
Ә кайчакта, һич кызганмый,
Колакны да боралар.

Тәрбиясез дисәм инде...
Әти, әни үзләре.
Кем өйрәткәндер аларга
Шундый кире сүзләрне?

Бер әйберне эшләр өчен,
Мең кат сорарга кирәк.
Минемчә, алар үзләре
Тәрбиясез бит бигрәк.

Ни булыр соң киләчәктә,
Мин охшасам аларга?
Гел киресен сөйләп торсам
Үземнең балаларга?

## Ачу килә акбурга

Ачу килә акбурга –
Җәлләми бер тапкыр да.
Тактага чыккан саен,
Гел «2» ле алдыра.
Сыйныфташлар алдында
Кыен хәлдә калдыра.

Югыйсә бит тактага
Чыгалар башкалар да.
Апабыз, мактый-мактый,
«5» ле куя аларга.

Белмим инде, акбурны
Ни эшләтеп карарга?
Ничек өйрәтим аны
Бер хатасыз язарга...

## Керән

Бакчага кергән Әкрәм,
Түтәлдә күргән керән.
Керәнне яратканга
Йолыккан берәм-берәм.

Керән күзләргә кергән,
Елап җибәргән Әкрәм.
Керән әйткән Әкрәмгә:
– Харап итмә әрәмгә.

Ашамасаң ашама,
Җиргә йолкып ташлама.
Тәрбиясез бала булу
Әнә шуннан башлана.

## Грипп куабыз

Ел саен безнең мәктәпне
Карантинга ябалар.
«Берүк, озак авырмагыз,
Терелегез, балалар...»

Ә без тимераякларда
Рәхәтләнеп шуабыз,
Сарымсак, суган ашыйбыз,
Шулай грипп куабыз.

Кайбер балалар, чынлап та,
Гади нәрсәне белми:
Спорт белән дус булсаң бит,
Бер чир дә якын килми.

## Карачкы ярдәм итте

Сап-сары бәбкәләр белән
Тулды ишегалдыбыз.
– Әни, – димен, – ник аларны
Бу кадәр күп алдыгыз?

– Син бит инде үстең, улым,
Бәбкә генә сакларсың...
Әниемнең ышанычын
Менә ничек аклармын?

Уйлый-уйлый баш ваттым да
Хәйләсен тиз таптым мин.
Бер карачкы ясадым да
Читтән карап яттым мин.

Каргалар да, тилгәннәр дә
Гел куркышып беттеләр.
Карачкыны әллә каян
Әйләнеп үк үттеләр.

Чөнки аның муенына
Мин язып элгән идем:
«Бәбкәләрне урларга һич
Ярамый» дигән идем.

## Кызык итте

Ялт та йолт
Килә яшен.
Нигәдер
Көлә яшен.

Күкләрне
Дер селкетә.
Табигать
Шифа көтә.

Яңгыры
Кая киткән?
Әллә соң
Кипте микән?

Тамып та
Карамады.
Нәрсәбез
Ярамады?

...Вәт яңгыр
Кызык итте:
Әйләнеп
Узып китте.



## Кар нигә яумый икән?

Кыштан куркып, кошлар китте,
Агачлар шәрә калды.
Бал кортлары күптән инде
Татлы йокыга талды.

Кар көтеп ята көрәкләр,
Чаңгылар һәм чаналар.
Кибетләрдә ялык-йолык
Гирляндалар яналар.

Календарьдагы көннәр дә
Азаеп бетеп килә.
Кыш бабай ник кар яудырмый,
Ягез, кайсыгыз белә?





## Әгәр дә сыер булмаса

Әгәр дә сыер булмаса,
Бер эшсез ятар идем.
Каймакны да, катыкны да
Кибеттән ашар идем.

Әгәр дә сыер булмаса,
Көтүгә йөрмәс идем.
Печән чапкан болыннарны
Гомергә күрмәс идем.

Әгәр дә сыер булмаса,
Вакыт күп калыр иде.
Белеп торам, ул вакытны
Ялкаулык алыр иде...



## Батырлыкта – матурлык

Малайларның, белеп торам,
Батыр buласы килә.
Ә кызларның, күреп торам,
Матур буласы килә.


Матурлык әле шулай да
Түгел бит ул батырлык.
Менә батырлык, ичмасам,
Үзе чып-чын матурлык.



## Иң тәмле йокы



Әллә нинди йокы миндә:
Беркайчан туя белми.
Ә ятканда, әкиятсез
Үзе яныма килми.
Тәмлелеге ягыннан да
Иң тәмлесе – минеке.
Әйдә бәхәс!
Җиталмый шул
Минекенә синеке.



## Үсеп кенә җитим

Алмашлап кулда йөртәсез,
Бәйлисез биләүләргә.
Ничек йокламыйсың инде
Бу кадәр көйләүләргә.

Ишетәм бит барысын да,
Әйтә генә алмыйммын.
Күпләрегез әртисләнә,
Барысын да аңлыйммын.

Уенчыклар белән алдап
Калдырасыз кайчакта.
Уңайсыз миңа бишектә,
Рәхәт сезнең кочакта.

Уңга-сулга тирбәтәсез,
Алга-артка йөртәсез.
Йоклагандай итәм инде:
Сез бит шуны көтәсез.

Уйлап ятам, тырышамын
Барыгызны аңларга.
Сабыр итегез әз генә,
Өйрәнермен алдарга.

Минем алдаганга сез дә
И куанырсыз әле.
«Безнең Булат шулай ул», – дип
Горурланырсыз әле.

## Кем уздыра этәчне?

– Кикрикүк, кикрикүк,
Кем кычкыра минем күк?
Кем уята йокыдан,
Шуңа хөрмәт, шуңа дан!

– Кикрикүк, кикрикүк!
Кемнәр дәртле минем күк?
Кем минем күк тырыша,
Тавыкка җим табыша?

– Кикрикүк, кикрикүк!
Кемнәр кызыл кәпәчле?
Купшы кием ягыннан
Кем уздыра этәчне?

– Кикрикүк, кикрикүк!
Сез йөрегез минем күк.
Һәрчак горур булыгыз,
Биеп кенә торыгыз.

– Ки-кри-кү-үк!



## Сәлам яздым Иделгә

Көймә ясап куйгач кына,
Гөрләвекләр киптеләр.
Әллә суы җиргә сеңде,
Белмим, кая киттеләр.

Язмыни бу, суларында
Бер батып та кермәгәч.
Рәхәтләнеп гөрләвектә
Көймә дә йөздермәгәч.

Көймәләрне әрәм итмим,
Ык суына саламын.
Идел елгасына кадәр
Барыр, бәлки, сәламем.

## Чыкмас миннән балыкчы

Әтием минем балыкчы,
Көн дә бара балыкка.
Урынын да белеп торам –
Ык буена, таллыкка.

Аның белән элегрәк
Баргаладым үзем дә.
Чиртмәгән көннәре булды,
Җитмәде түзем генә.

Әтиемә исем китә:
Кайчак балыгы да юк,
Ә борыны һич салынмый,
Үзе шаян, үзе шук.

Балыкны бик яратсам да,
Чыкмас миннән балыкчы.
– Әти, кибеткә керик тә
Сатып кына алыйкчы...

## Кайда син, Кыш бабабыз?

Кар төшә дә эреп бетә,
Күрмичә дә калабыз.
Кайда йөри икән соң бу
Аксакал Кыш бабабыз?

Җәяүлегә юл ерак шул,
Кагылмый китмәс әле.
Елына бер килгән кыштан
Мәхрүм итмәс әле.

## Кыш бабайга

Хәйләкәрме, усалмы син,
Аңлап булмый холкыңны.
Җылы кием белән генә
Алдап булмый салкынны.

Кошлар да очмый һавада,
Алар да бит туңадыр,
Төтен чыккан морҗаларга
Җылынырга кунадыр.

Масаеп китмә, Кыш бабай,
Син шуны беләсеңме:
Безнең чыршы бәйрәменә
Кунакка киләсеңне?

## Менә сиңа шугалак

Яңа елга матур итеп
Ясап куйдык шугалак.
Өлкәннәр дә йөрде әле
Шугалакта шугалап.

Ә беркөнне иртә белән
Карасак шугалакка,
Без шуып йөргән мәйданчык
Әйләнгән сугалакка.

Төн эчендә юкка чыккан
Менә дигән шугалак.
Керә күрмәгез сез анда,
Ул бит хәзер – чумгалак.



## Кышкы кояш

Яктыртуын яктырта да,
Җылытмый җылытуын.
Үзе киеп куйган бугай,
Бик туңгач, җылы тунын.

Тавыкларның җыры тынды,
Сыер гына мөг(е)ри,
Тәрәзләрдә сары песнәк
Безгә кызыгып йөри.

Карга көтүләре тынды,
Һавада юк болыт та.
Агачлар йокыга киткән,
Төренеп ак толыпка.

Җир генә кояш тирәли
Эзләми бер хәйлә дә,
Хыянәт итми эшенә:
Әйләнә дә әйләнә.



## Әләмдә алма төсе

Әләмебез әллә инде
Табигатьтән яралган:
Бакчабызда үсә торган
Җимешләр төсен алган.

Алмабызны гына карыйк:
Яшел яфрак яра да
Ап-ак чәчәккә күмелә.
Ул төс ике арада.


Аннан кып-кызыл алмалар
Белән сыйлый алмагач.
Әләмебез мәңгелек шул,
Кызык икән аңлагач.



## Сыерчык нигә сайрый?

– Сыер, чык,
Сыер, чык, –
Дип сайрагач сыерчык,
Чыкты сыер абзардан,
Куркып китте казлардан.
Аз гына ыс-с-лаштылар,
Аннан соң дуслаштылар.
Язгы матур көн белән
Бер-берсен котлаштылар.
Сыерчык та сыерны
Котлый-котлый сайрады.
Очып төшеп сыртына,
Йон-ябага сайлады.
Җыйды да томшыгына,
Оясына илтте ул.
Килә-китә, килә-китә,
Шундый кызып китте ул...
Сыерны шыр шәрәгә
Калдырамы дип торам.
Аклы-каралы тунын
Салдырамы дип торам.
Ә сыер селкенми дә,
Әллә инде белми дә
Ябагасын алганын,
Шәрәләнеп калганын.

Шунда гына аңладым
Ни өчен ул сыерчык,
Килә дә безгә очып,
Абзарга карап сайрый:
– Сыер, чык та, сыер, чык!..



## Африкада кар яуган

Африкада кар яуган, ди,
И кызык та булгандыр.
Яланаяк йөрүчеләр
Нишләгәндер?
Туңгандыр.

Ап-ак карны күрү белән
Куркуга калганнардыр.
Энҗедәй кар бөртекләрен
Кулга да алганнардыр.

Безнең кебек, кар бабайлар
Ясый белделәр микән?
Әллә кар атышып кына
Уйнап йөрделәр микән?

Үзем булсам... Мин аларга
Зур таулар өяр идем.
– Чын кышны күрергә, безгә
Килегез, – дияр идем.



## Иң кыска ел фасылы

– Ел фасылының кайсысы
Иң кыска? – дип сорадым.
Булат кыю җавап бирде,
Һич тә уйлап тормады.

– Билгеле инде «яз» була,
Син аны белмисеңме?
Ике генә хәрефле бит,
Шуны да күрмисеңме?

## Әтиләр үкенгәндер

Авылыбыз күптән газлы,
Чишмә суы һәр өйдә.
Җәен кунакка кайта да
Гаҗәпләнә Фәридә.

– Былтыр монда елга иде,
Быел күл ясалган, – ди.
– Кемдер аңа төрлесеннән
Балыклар да салган, – ди.

Сандугачлар сайрап тора,
Балык тота балалар.
Кармакларга күз иярми:
Салалар да алалар.

Асфальт юл төзеп яталар,
Яшел чирәм җитәрлек.
Кыскасы, Фәридәбезнең
Ис-акылы китәрлек.

– Безнең шәһәрдә дә шундый
Авыл булсын иде, – ди.
– Күлләр буенда сандугач
Сайрап торсын иде, – ди.

– Әтиләр ялгышып кына
Шәһәргә күченгәндер.
Белеп торам: соң булса да,
Үзләре үкенгәндер.



* * *

Озынборынның борыны
Исеменнән кыскарак.
Кем икән соң исем биргән,
Шундый борынга карап.

Менә филнең борыны бит
Югыйсә җиргә тигән.
Исемендә «борын» да юк,
Кемдер бары «фил» дигән.

«Озынборын» озын булгач,
Тагын исем тапканнар:
Нечкә генә, кыска гына
«Черки» диеп такканнар.

* * *

Ап-ак тупыл мамыклары
Тирбәлешеп җилләрдә,
Төшәр-төшмәс уйнап йөри
Яшел чирәм җирләргә.

Тупыллар мамык очыра:
Очамыни ак карлар!
Бәбкәләр кызыгып тора:
«Безгә дә мамыклар үссә,
Булыр идек ак казлар».

## Пешергәнмен тәбикмәк

Әни пешерде коймак,
Мин дә йөрмәдем уйнап.
Әни белән кайнаштым,
Коймакларны майлаштым.

Үзем дә камыр алып,
Кызган табага салып,
Осталыкны тикшердем –
Зур бер коймак пешердем.

Бик мактанасым килде,
Әни шатланып көлде.
Һәм әйтте: «Менә хикмәт –
Булган ич бу тәбикмәк!»

## Булат кучтәнәч көтә

Беркөн Булатның борыны
Кычыткан бит нигәдер.
Шатлыгыннан сикерде ул:
– Безгә кунак киләдер!..

Кашый-кашый, ул борынын
Кызартып ук бетерде.
Тик кунаклар күренмәде,
Көттерде дә көттерде.

– Кунак килмәсә дә, миңа
Бер чара күрегез, – ди, –
Кибеттән кучтәнәч алып
Китереп бирегез, – ди.

## Күчерсәң күчер инша

Татар теле дәресендә
Укытучы эш биргән:
– Үз гаиләгез турында
Инша языгыз, – дигән.

Гадәтенчә, иншасына
Кыям көчен куймаган.
– Күчерермен әле шунда, –
Диеп кенә уйлаган.

Хәрефен дә үзгәртмичә
Күчергән ул иншаны.
Ә укытучы тактага
Чыгарган, ди, нәкъ аны.

Инша бар бит. Укый Кыям
Чит бер гаилә турында.
Дуслары эч тотып көлгән,
Утыралмый урында.

– Ярар, – дигән укытучы.
– Шәп язгансың бит, Кыям.
Күршең Салаватка «5» ле,
Сиңа «2» ле куям.



## Кайда икән мөгезе?

Әллә сизмичә калганмы,
Адашканга да охшый.
Ялт иттереп безнең янга
Килеп чыкты бер поши.

Ә мөгезе? Кая куйды
Микән соң ул мөгезен?
Мүкләк пошиларны бер дә
Күргән юк иде безнең.

Мөгезен ул югалткандыр,
Шуны эзләп йөридер.
Бик борчылган һәм арыган,
Шуңа безне күрмидер.

Ул пошига ничек итеп
Ярдәм итәр идегез?
Беләсезме, кайда ята
Поши югалткан мөгез?

*(Ана пошиларның
мөгезләре булмый.)*



## Авылдагы ай

Авылга кайткач, мин быел
Шундый олы ай күрдем.
Ай икәнен әле аның
Бабайдан гына белдем.

Беләсеңме, ул бит безнең
Табактан артык иде.
Ә төсе бакчабыздагы
Алмага тартым иде.

Күтәрелгән саен күккә,
Кечерәйде алай да.
Бездәгедәй булып калды
Авылдагы ул ай да.

## Беренче сентябрь

Беренче сентябрь – безгә
Бәйрәмнең дә бәйрәме.
Һәрберебезнең кулында
Күпме чәчәк бәйләме.

Укытучы апалар да
Елмаеп, көлеп тора.
Шатлыгыбыз эчкә сыймый,
Алар да белеп тора.

Бәйрәм булгач бәйрәм инде,
«2» ле дә куймыйлар.
Хәтта өй эшен бирергә,
Орышырга кыймыйлар.

Шаярабыз рәхәтләнеп,
Сөйләшеп туялмыйбыз.
Кызык хәлләр искә төшә,
Авызны җыялмыйбыз.

Беренче сентябрь бүген,
Мәктәп гөр килеп тора.
Һәрберебезнең йөзеннән
Шатлык бөркелеп тора.

## Бүген безнең туган көн

Бабамның туган көнендә
Минем дә туган көнем.
Бабама алтмыш, ә минем
Алты яшь тулган көнем.

Гел исемдә булды ул көн,
Барыбер онытмадым.
Әтиләрдән дә алдарак
Бабамны мин котладым.

Бабам шунда күтәрде дә
Аркамнан сөйгән була.
«Рәхмәт, улым, мин бит синнән
Көнләшәм», – дигән була.

Көнләшергә... Мин бит әле
Укырга да кермәгән.
Аның кебек медаль тагып,
Дөнья гизеп йөрмәгән.

Менә мин көнләшәм аннан,
Горурланам, мактанам.
Бер дә килмәгән җире юк,
Чөнки ул – минем бабам.

Бабама бүген алтмыш яшь,
Миңа алты тулачак.
Ә табында урыныбыз
Бүген бергә булачак,
Әле түрдә булачак.
Белдеңме?!



## Чын Кар кызы

Яңа ел җитәр алдыннан
Ялкауланып ятмыйбыз.
Сыйныфташларыбыз белән
Кардан сыннар ясыйбыз.

Үсеп чыга ак аюлар,
Кабаннар, ташбакалар.
Күз ачып йомган арада,
Крокодиллар калкалар.

Шундый охшатып ясадык
Кыш бабайның да сынын.
Бастырып куйдык янына
Кар кызының чып-чынын.

Безнең сыйныф кызы шул ул,
Бик килешә үзенә.
Чәчләрендә ап-ак карлар,
Тимәсен тик күз генә.



## Булатның бәбкәләре

Булатның әбисе язын
Егерме бәбкә алды.
Аларны саклау, ашату
Бары Булатка калды.

Тилгән-фәлән алмасын дип,
Булат көн дә санады.
Күзләре тилгәндә булды,
Башкага күз салмады.

Беркөн шулай егермегә
Тулмады бәбкә саны.
Йөз кат санап караса да
Чыгаралмады аны.

Беренчегә керде Булат,
Бәбкәләр каз булдылар.
Егермегә тулмадылар,
Нәкъ бергә аз булдылар.

Бер бәбкәне югалтса да,
Җәе үтмәде бушка.
Егерме эчендә Булат
Тиз ала һәм тиз куша.



## Витаминлы бакчабыз

Җәй җиттеме, бакчабызда
Витамин тулып тора.
Берсе бетсә, икенчесе
Өлгереп, булып тора.

Җиләк-җимеш, яшелчәнең
Һәрберсендә витамин.
Кайсында А, кайсында В,
Барысын да әйталмыйм.

Әни әйтә: – Витаминнар
Кешене үстерә, – ди.
– Кайсы акылны арттыра
Йә тәнгә көч бирә, – ди.

– Витаминнарның һәрберсен
Юып ашау зарур, – ди.
– Минем сүзне тыңламаучы
Авыруга тарыр, – ди.

Дөрес әйтә минем әни,
Ул бит шәфкать туташы.
Витаминның төрлесенә
Бай була аның ашы.

Гел минем файдага гына
Бу җәйләр үтсен әле.
Сулар сибим: витаминнар
Күп булып үссен әле.

## Безнең теләк

Тәнәфесләр дәрес кебек
Озын булсалар иде.
Шаярганга карап кына,
Билге куйсалар иде.

Өй эшләрен теләгәннәр
Генә үтәсен иде.
Каникуллар сизелмичә
Бетеп китмәсен иде.

Көндәлекләргә көн саен
«5» ле куйсыннар иде.
«2» лене мәктәпләрдән
Ерак кусыннар иде.

Туңдырма һәм шоколадлар
Тулып торсыннар иде.
Безнең ниләр теләгәнне
Белеп торсыннар иде.

Шул вакытта мәктәпләргә
Барасы килер иде.
Ә белергә теләгәннәр
Барыбер белер иде.

## Җәяүле буран

Буран турында сөйләсәм,
Беләм инде, көләрсез.
Бездәге бураннарны бит
Сез болай да беләсез.

Шул буранны, мескенкәйне,
Шундый кызык иттем мин:
Кызганмадым, чаңгыма да,
Чанама да җиктем мин.

Якшәмбе көн аның белән
Җитәкләшеп йөгердек.
Кәшәкәле уйнап йөрдек,
Кибетләргә дә кердек.

Әле мәктәптән кайтканда,
Көтеп тә торган иде.
Шуңа күрә дә ул буран
Җәяүле буран инде.



## Җил

Җилбер-җилбер җилбәзәк,
Җилпәзәле илгәзәк.
Җәяүле дә, атлы да,
Җилфердек канатлы да.



## Солдат буласым килә

Әгәр мин солдат булсам
Һәм чиктә постта торсам,
Керфек тә какмас идем,
Ватанны саклар идем.

Әгәр мин солдат булсам,
Билемә каеш бусам,
Чын егет булыр идем,
Син дә сокланыр идең.

Әгәр мин солдат булсам,
Шат булыр иде ил дә.
Шуңа күрә дә минем
Постта торасым килә,
Солдат буласым килә...

* * *

Мин җиләкне яратканга,
Авызга тутырамын.
Әни ачулангач, әйттем:
– Соң бит ялгыш
Авызымны
Чиләк диеп торамын.

## Кунарга килә икән

Көне буе әзерләнде:
Көчле җилләр истерде;
Ялгыз йөргән болытларны,
Җыеп, безгә китерде.

Бабайның да буыннарын
Сызлаттырып бетерде.
Бу яңгыр бик көйле булды:
Көттерде дә көттерде.

Бабам һаман өметләнә,
Гаҗәпләнәм шуңарга.
– Болай булгач, бу яңгыр, – ди, –
Килә икән кунарга...



## Карусельдә рәхәт икән

Карусельгә утырдым да
Менеп киттем югары.
Сезнең андый биеклеккә
Менгәнегез юк әле.

Бөтен шәһәр уч төбендә,
Шаккатып карап торам.
Сөембикә манарасы,
Тегесе – безнең урам...

Ул кешеләр әллә нишләп
Кырмыскадай вак кына.
Этләр дә күзгә чалына,
Күренәләр чак кына.

...Космоска кадәр җитәрлек
Карусель булса иде.
Җиребезгә рәхәтләнеп
Бер карап торсаң иде...



## Рәхәт соң коену

Киемнәрне салдым да,
Яп-ялангач калдым да,
Бер чиләк су алдым да
Куйдым аны алдыма.
Утырдым да хәл җыеп,
Куркуны читкә куеп,
Таманлап салкын суны
Җибәрдем баштан коеп.
Карап торган энекәш
Шатлыгыннан кул чаба.
Рәхәт тә соң коену
Үзебезнең мунчада.



## Тәгәрмәчле тимераяк

Бабамнарның авылына
Быел асфальт җәйделәр.
Кунак малай, кунак кызлар
Бермә-бер күбәйделәр.

Шунсы кызык: ул кунаклар
Берсе дә буш кайтмыйлар.
Сәпиттә дә, матайда да
Чабалар, тик ятмыйлар.

Башта мин дә сәпитемне
Алып кайтмакчы идем.
– Юк шул әле, авыл халкы
Бер кызык күрсен, – дидем.

Тәгәрмәчле тимераяк
Алып кайттым да тактым.
Оялып-нитеп тормадым,
Асфальт юл буйлап чаптым.

Көтүдән кайткан сарыклар
Гел өркешеп беттеләр.
Әби-бабайлар, туктатып,
Пыр туздырып сүктеләр.

Нихәл итим, беркемне дә
Шаккатыра алмадым.
Авылдагы тәртипләрне
Шунда гына аңладым.

## Менә сиңа ат

Бабам җигеп биргән атта
Булдым йөреп карарга.
Утырып кына өлгердем,
Тотынды ат чабарга...

Дилбегәне тартып карыйм:
– Тукта инде, тр-р, тр-р, – дим.
Арттан бабай чаба аксап:
– Уңга таба бор, бор! – ди.

Кая борасың ди монда,
Ат бит мине тыңламый.
Чабуын гына белә ул,
Туктарга һич уйламый.

Күл буеннан үткән чакта,
Сикереп төштем суга.
Ат, арбасын шалтыратып,
Кереп китте басуга.

Су су инде, җиргә төшсәм,
Аяксыз калыр идем.
Сентябрьдә ничек итеп
Мәктәпкә барыр идем?

Манма су булып чыгуга,
Бабам да килеп җиткән.
– Бәхетемә каршы, – ди, – син
Алай да исән икән...

И шатланды шунда бабам,
Мине кочаклап сөйде.
Каршы килгән атны күреп:
– Үзе кайта ул... – диде.



# Язын җил ник котыра?

Яз җиттеме, җил котыра,
Каян гайрәт ала ул?
Дөньяларны дер селкетеп,
Чын куркуга сала ул.

Телевизор да күрсәтми,
Өйләрдә утлар сүнә.
Чыпчыклар нидер серләшеп
Сыена бер-берсенә.

Беләсезме, язын нигә
Җилләр ярсу икәнен?
Җил – хәйләкәр, көтеп ятмый
Кышның үзе киткәнен.

– Җитте, – ди ул. – Озак яттың.
Язга да урын бир, – ди.
– Капчыгыңны ас та әнә
Төньягыңа йөгер, – ди.

## Җилне тыярга кирәк

Җилне җигәргә кирәк,
Җилне җиңәргә кирәк.
Көче белән масая,
Безне санламый бигрәк.

Ком бураны туздыра,
Агачларны сындыра.
Түбәләрне селкетеп,
Колакларны тондыра.

Сызгыра йә үкерә,
Әдәп саклап тормый ул.
Элеп куйган керләрне
Күз ачканчы урлый ул.

Җилне тыярга кирәк,
Җигеп куярга кирәк.
Өлкәннәргә бу турыда
Нидер уйларга кирәк!

## Яңгыр

Урман артыннан чыкты да
Йодрык кадәр ак болыт
Әй кабарырга тотынды,
Бөтен күкләргә тулып.

Җилләр исте. Ул кабарды,
Ачуланды, каралды.
Якты яшен камчысыннан
Нәкъ урталай ярылды.

Ярылып кына калмады,
Аннан яңгыр яралды.
Коеп-коеп яуган иде,
Болытлар да таралды.

Салават күпере аша
Яңгыр китеп югалды.
Сусап беткән болыннарга
Һәм кырларга юл алды.



## Яңа ел каян килә?

Яңа ел ул каян килә:
Һаваданмы, җирдәнме,
Тауларданмы, урманнанмы,
Әллә берәр илдәнме?

Ә иске ел кая китә,
Оча микән космоска?
Аның бит инде болай да
Гомеркәе кып-кыска.

Сорауларга җавапларны
Барыбер табачакмын.
Керфек какмый, Яңа елны
Мин каршы алачакмын.
Ә искесен күз дә йоммый
Озатып калачакмын.



## Безнең Идел

Безнең Идел диңгез түгел,
Шулай да ул дулкынлы.
Яр буйлары кыя-кыя,
Кай җирләрдә ул комлы.

Безнең Идел диңгез түгел,
Ә шулай да балыклы.
Безнең Идел Идел инде,
Океаннан да данлыклы.

## Иң кызу көн

– Кояш кайчан шәп кыздыра?
– Җәен инде, челләдә.
– Җәен түгел, сентябрьдә,
Без укыган бүлмәдә.

Әбиләр чуагы җитсә,
Утырып булмый бер дә.
Шулай булгач,
Иң кызу көн,
Билгеле, сентябрьдә!

## Чикерткә сайрый өйдә



Чикерткә кергән өйгә,
Өйгә кергән ул нигә?
Тышта азык беткәнме,
Ямьле җәйләр үткәнме?

Тыныч кына яшәсә,
Әйтмәс идең бер сүз дә.
Кич җитсә, уйный башлый
Оркестр өебездә.

Бу, бәлки, чикерткәнең
Йорт өчен түләведер.
Сайравы безгә бәхет
Һәм гомер теләведер.

Ничек кенә булса да,
Сайрап кына торса да,
Без чикерткәдән туйдык
Һәм аңа бер шарт куйдык.

Йә сайраудан туктыйсың
Һәм төннәрен йоклыйсың.
Үтәмәсәң, рәхим ит:
Ишек ачык – чыгып кит!



## Туган телем

Сабый чактан ук кадерен
Әллә каян белгәнмен:
Туган телдә елаганмын,
Туган телдә көлгәнмен.

Туган телемдә иркәләп
Назлаганнар, сөйгәннәр.
Туган иленең лаеклы
Улы булсын, дигәннәр.

Туган телем, моңга төреп,
Бишекләрдә тирбәткән.
Кешелеген җуймасын дип,
Акыл-гыйлем өйрәткән.

Туган телем – милләтемнең
Тамыры да, гөле дә.
Туган телсез гомеремнең
Үтмәсен бер көне дә.

## Җил башкара барын да

Җил җитешмәгән җирләр юк,
Җил шәһәрдә, авылда.
Җилдән туа гарасат та,
Җилдән туа давыл да.

Җил китерә яңгырын да,
Җил китерә карын да.
Җил белмәгән бер эш тә юк,
Җил башкара барын да.

Кояш көлеп карап тора
Җилнең кыланышына.
Ә бәяне без бирәбез
Аның кылган эшенә.

## Шикәр авылда үсә

Балның каян табылганын
Барыбыз да беләбез.
Ә шикәр каян килә соң?
Шул турыда сөйләгез.

Шикәр комын кибетләргә
Капчыклап кайтаралар.
Аның өчен машиналар
Зур шәһәргә баралар.

Ә шәһәрдә шикәр комын
Каян алалар икән?
Нефть кебек җир астыннан
Гына табалар микән?

Табар сиңа... Җир астында
Шикәр була димени?!
Безнең авылның шәһәрдән
Берәр җире киммени?

Шикәрне дә авыл бирә,
Басуларда үсә ул.
Шикәр чөгендере булып
Заводларга күчә ул.

Ә заводта чөгендерне
Көтеп кенә торалар.
Яхшылап эшкәртәләр дә
Капчыкка тутыралар.

Шикәр шулай урау юллар
Үтеп кайта табынга.
Шикәргә һич интекмәссез,
Без авылда чагында.

# Минем бабам – гармунчы

Бабамның бар
Гармуны.
Сыйдырган ул
Бар моңны.

Уйный бабам,
Сыздырып.
Барыбызны
Уздырып.

Җырлый кайчак
Үзе дә.
Биеткәли
Безне дә.

Юмартлыгы –
Йөзендә.
Чаялыгы –
Күзендә.

Гармун сезгә
Кала, ди.
Уйнасын һәр
Бала, ди.

Онытмагыз
Тик шуны:
Бу – бабамның
Гармуны.

Мин аны нык
Сакладым:
Югалтмадым,
Ватмадым.

Инде сезгә
Чират, ди.
Гармун булыр
Мирас, ди.

Бабам сүзен
Ничек тә
Ташламабыз
Без читкә.

Гармунны да,
Моңны да
Без киләсе
Буынга

Тапшырырбыз
Китереп,
Бабам төсе
Иттереп.



# Телебезне төзәттеләр

Үз телемне беләм диеп
Йөргән булдым.
Хәтта кайбер малайлардан
Көлгән булдым.
Дәресләрдә «4» ле, «5» ле
Генә алдым.
Шигырьләрне матур сөйләп,
Мин макталдым.
Ә беркөнне шундый кыен
Хәлдә калдым.
Дустым белән бабайларга
Барган идек,
Әллә ничек... кунарга да
Калган идек.
Шунда безнең сөйләшкәнне
Тыңлаганнар.
Үзләренчә тел белүне
Сынаганнар.
Мин «бабай» да «әби» диеп
Йөргән булам.
«Әти», «әни» дип сөйләшкәч
Әйбәт сыман.
Дустым исә әбиләргә
«Әбекәй» ди.
Әниләргә «әни» дими,
Ә «әнкәй» ди.
«Рәхмәт» сүзе «рәхмәт яусын»
Була икән.

Үз телеңне яхшы белү
Шулай икән.
Ярый әле әбекәйләр
Күзәтteләр.
Рәхмәт яусын, телебезне
Төзәтteләр.
Тәмле итеп сөйләшергә
Өйрәтteләр.

## Бәхетле мин

Туган җирем – Татарстан,
Казан – минем башкалам.
Газиз илем, мин бит синең
Бик бәхетле бер балаң.

Туган телем – татар теле,
Тукай, Туфаннар теле.
Әйтерсең ул – милләтемнең
Иң матур сулмас гөле.

Бәхетле мин. Әллә инде
Канатым бар иңнәрдә.
Очып китәр төсле булам
Ерак-ерак илләргә.


Юк, кирәкми чит-ят җирләр,
Туган илгә ни җитә.
Туган илнең җилләре дә
Безне бәхетле итә.

## Велосипедлы сыер

Әти йөри машинада,
Ә абыем – матайда.
Минем дә бар велосипед,
Кирәкми бензин, май да.

Сыерыбыз көне буе
Җәяү йөри көтүдә.
Шуңа күрә көзгә таба
Кими инде сөте дә.

Аңа да бер велосипед
Табып бирергә иде.
Велосипедлы сыерны,
Их, бер күрергә иде!..



* * *

Кояшны кызык иттем,
Тоттым да эшкә җиктем.

– Печәнне киптер, – дидем, –
Җиләкләр пешер, – дидем, –
Кызудан туйганнарга
Күләгә төшер, – дидем.

Ә ул кызып эшләде:
Баш очыннан төшмәде.
Тик җиләкнең берьюлы
Барысы да пешмәде.

Бөтенесен бер көндә
Үтәп булмый, дигәндер.
Көне буе эшләгәч,
Йокысы да килгәндер.

...Җиргә биреп бар көчен,
Йокларга китте кичен.

## Күркә

Наратта да, чыршыда да,
Әбидә дә бар күркә.
Шул күркәләрнең берсеннән
Безнең Камилә курка.


Кайсы күркәдән куркадыр,
Яле, әйтеп бирегез.
Андый күркәләрне сез дә
Урабрак йөрегез.

## Кояш

Кояшлы көнгә ни җитә,
Кояшта бөтен хикмәт.
Кояшның алтын нурына
Үрелеп үсә икмәк.

Кояш җиләкләр пешерә,
Кояш печән киптерә.
Кояшлы иртә күлләрдә
Балыкларны чирттерә.

Яңгырга да кояш кирәк,
Кояшсыз булмый болыт.
Салават күпере чыккан,
Кояшка бүләк булып.



## Алма ашарга кирәк

«Алма аша, – диләр, – алма,
Тимер керер тәнеңә».
Алма ашыйм, ләкин килми
Тимернең бер тәме дә.

Тәнгә тимер керсә, кеше
Сәламәт була икән.
Сәламәт кешеләр бик күп
Игелек кыла икән.

Матур кеше булу өчен,
Беләм, кирәк игелек.
Игелекне кылу өчен,
Алма ашыйм иң элек.

## Тычкан да алданмаган

Сыр куйганнар капкынга,
Берәр тычкан капсынга.
Күрсәтмәгәннәр хакын,
Тычкан килмәс дип якын.

Бушлай сыр күргәч тычкан,
Шикләнгән, коты очкан.
Бу юньле хәл түгел дип,
Өенә кереп поскан.

## Ур-ра, физкультура!

Чабышабыз өстә, аста,
Йөгерәбез турыга.
Ашыгабыз тәнәфестә
Шулай физкультурага.

Тезеләбез, бөгеләбез,
Шаярабыз, көләбез.
Физкультура – сәламәтлек,
Аны яхшы беләбез.

Тимераякта шуабыз,
Туплар белән уйныйбыз.
Физкультура дәресендә
Әз генә дә туймыйбыз.

Башка фән үпкәләмәсен,
Яшәсен физкультура.
Бүген бәйрәм – физкультура.
Ура, малайлар, ур-ра!..



## Бөрлегән утырттык

Бакчабызга утырттык без
Чәнечкеле бөрлегән.
Чәнечкесе чәнечке дә,
Ә җимеше бер дигән!

Кыяфәте кура җиләк,
Ә төсләре кап-кара.
Тел йотмалы тәмле үзе,
Йә әле кабып кара...

– Минем яннан узган чакта,
Күзең ачып йөр, – ди ул.
Кызыктыра, үзе чәнчи,
Менә шулай үрти ул.

## Имеш, мөгез чыга, ди

Әни мине ачулана:
– Белмисең чамасын, – ди, –
Кунак килсә, син һәрвакыт
Мөгез чыгарасың, – ди.

Мөгез чыгарырга инде,
Мин әкәм-төкәммени?
Мөгез чыгармасам, миңа
Башка эш беткәнмени?

Мөгез чыкса, мин аны бит
Үзем дә сизәр идем.
Ялгыш кына булса да,
Берәрсен сөзәр идем.

Миңа бит мөгез чыкканны
Башкалар күрер иде.
Күреп кенә дә калмаслар,
Шаркылдап көләр иде.

...Бәлки, әни алдамыйдыр,
Чынлап чыгадыр мөгез.
Кунак килгәч, күзәтегез
Әле мине үзегез.
Яме?

## «Аждаһа»* очырдым

Авылга кайттым да
«Аждаһа» очырдым.
Вак-төяк малайның
Котларын очырдым.

Очып та куйды соң,
Койрыкларын болгап.
Болытларга кадәр
Омтылды ул, дулап.

«Аждаһа» бервакыт
Туктады очудан.
Түбәнгә юнәлде
Җил тынган ачудан.

## Кыш та, җәй дә чаңгыда

Кыш җиттеме, әти белән
Без чаңгыда шуабыз,
Трамплиннан сикерәбез,
Шатланабыз шуңа без.

Ә җәй җитсә, әти тагын,
Яңа чаңгысын алып,
Иделгә йөзәргә китә,
Мин утырам таң калып.

Көймәләргә тагыла да
Йөзеп йөри чаңгыда.
Әтиемә сокланамын:
Курыкмый бер тамчы да.

Кызык икән, чаңгыларны
Яратсаң чын күңелдән:
Шуасың да, очасың да,
Йөзәсең дә Иделдә.

---

«Аждаһа» – җилле көндә очыртып уйный торган уенчык. Гадәттә, кәгазьдән яисә юка тукымадан (капрон) эшләнә. Кулдан ычкынып китмәсен өчен, тоткыч урынына җеп кулланыла.

## Алинә кунак ярата

Алинәнең бар белгәне
Кунак та кунак кына.
Чөнки аны дәү әнисе
Тора гел сыйлап кына.

Кунакның да чиге була,
Кичен: «Өйгә кайтам», – ди.
Өйгә кайткач: «Без кунакка
Барабыз соң кайчан?» – ди.

## Кояшыбыз тулып торсын

Ай бик кызык икән бит ул,
Яңа килеш туа да
Аннан тула-тула да,
Түп-түгәрәк була да,
«С» хәрефен хәтерләтеп,
Искерә дә югала.

Кояшыбыз, берүк, айдан
Үрнәк ала күрмәсен.
Тулган килеш туып торсын,
Ай кебек искермәсен.

## Әтәч бирде кирәкне

Бүген минем ак әтәчкә
Шундый килде ачуым.
Иртән торып, кетәклектә
Булды ишек ачуым,

Сикереп кунып, канатларын
Әй бәрергә тотынды.
Мин йомыркага дип кердем,
Ә ул алды котымны.

Югыйсә бит ул әтәчне,
Чеби булган чакларда,
Туры килгән иде миңа
Каргалардан сакларга.

Әтәч булдым дигәч тә бит,
Әтәчләнү ярамый.
Әтәч халкы әллә инде
Яхшылыкны аңламый?



Быел да бит чебиләргә
Мин хуҗа булачакмын.
Тилгән, карга килә икән,
Аларны куачакмын.

Ачу килсә, чебиләрне
Ташлармын да китәрмен.
Кикриге шиңәр әтәчнең,
Сагынырлык итәрмен.





## Эш көлеп кенә тора

Эшләсәм, минем кулымнан
Эш килеп кенә тора.
Мин эшләгән эш нишләптер
Гел көлеп кенә тора.

Идән юам, утын кертәм,
Ишегалды себерәм.
Әнинең акчасын тотып,
Кибетләргә йөгерәм.

Мактап тора әтием дә:
– Булдырасың, улым, – ди.
– Һич арттырмыйм, бүгеннән үк
Син минем уң кулым, – ди.

Шулай инде, мин эшләгән
Эш көлеп кенә тора.
Ышанмасаң сүзләремә,
Күршеләремнән сора.

## Көз

Сары яфраклар серләшә
Урманда кыштыр-кыштыр:
«Язлар килмәс инде хәзер,
Чиратта салкын кыштыр».

Сирәк-мирәк кенә шунда
Каркылдый ала карга:
«Яфраклар, җиргә төшегез,
Күп калмады ак карга».

Салкын җилләр яфракларны,
Йолкып, җиргә төшерә.
«Онытмагыз кыш киләсен», –
Диеп искә төшерә.

## Бал корты

Өйдән дә чыгармый,
Бакчага кертми ул.
Беркемне җәлләми,
Битлексез йөртми ул.

## «Әни» сүзе

Иң матур сүз,
Иң рәхәт сүз,
Беләсезме, ни була?
Әллә каян сизеп торам:
Әлбәттә, «әни» була!

## Күрми калам йокыны

Әллә нигә йоклап булмый,
Йомып карыйм күзне дә.
Саный-саный узып киттем
Туксанны да, йөзне дә.

Әни, йокың килгән диеп,
Әллә алдашты микән?
Әллә йокы бирәр өйгә
Кереп адашты микән?

– Йокы, син кайда йөрисең?
Яхшы чакта килеп җит.
Мин бит начар малай түгел,
Ышанмасаң, күреп кит.

# Эчтәлек


Шундый туган як … 3
Кояш җәйгә хәл ала… 3
Салкын керләр киптерә … 4
Сәбәбе нидә икән? … 5
Кунаклар белән генә … 5
Их, кар яуса! … 6
Чаңгы шудым … 6
Бүре бүрек … 7
Зоопарк ачтык без … 8
Аллы-гөлле яз килде … 11
Мавыктыргыч галәм … 12
Атлар … 13
Тәрәзле телефон … 13
Усал шул минем апам … 14
«2» ле алгач … 15
Рәхмәт рәхәт икән … 15
Һич төшенмим … 16
Ачу килә акбурга … 16
Керән … 17
Грипп куабыз … 18
Карачкы ярдәм итте … 18
Кызык итте … 19
Кар нигә яумый икән? … 20
Әгәр дә сыер булмаса … 20
Батырлыкта – матурлык … 21
Иң тәмле йокы … 21
Үсеп кенә җитим … 22
Кем уздыра әтәчне? … 23
Сәлам яздым Иделгә … 24

Чыкмас миннән балыкчы ............... 24
Кайда син, Кыш бабабыз? ............... 25
Кыш бабайга ............................... 25
Менә сиңа шугалак ...................... 26
Кышкы кояш ............................... 26
Әләмдә алма төсе ........................ 27
Сыерчык нигә сайрый? ................. 28
Африкада кар яуган ...................... 29
Иң кыска ел фасылы ..................... 30
Әтиләр үкенгәндер ........................ 30
«Озынборынның борыны...» ........... 31
«Ап-ак тупыл мамыклары» ........... 31
Пешергәнмен тәбикмәк ................. 32
Булат күчтәнәч көтә ..................... 32
Күчерсәң күчер инша .................... 33
Кайда икән мөгезе ........................ 34
Авылдагы ай ................................ 35
Беренче сентябрь ......................... 35
Бүген безнең туган көн ................. 36
Чын Кар кызы ............................. 37
Булатның бәбкәләре ..................... 38
Витаминлы бакчабыз .................... 39
Безнең теләк ............................... 40
Җәяүле буран ............................... 41
Җил ............................................. 41
Солдат буласым килә .................... 42
«Мин җиләкне яратканга...» ......... 42
Кунарга килә икән ........................ 43
Карусельдә рәхәт икән .................. 44
Рәхәт соң коену ........................... 45
Тәгәрмәчле тимераяк .................... 46
Менә сиңа ат ................................ 46

Язын җил ник котыра? .................... 48
Җилне тыярга кирәк ....................... 49
Яңгыр ........................................ 49
Яңа ел каян килә? ......................... 50
Безнең Идел ................................ 51
Иң кызу көн ................................ 51
Чикерткә сайрый өйдә .................... 52
Туган телем ................................ 53
Җил башкара барын да .................... 53
Шикәр авылда үсә ......................... 54
Минем бабам – гармунчы ................. 55
Телебезне төзәттеләр ..................... 56
Бәхетле мин ................................ 57
Велосипедлы сыер ......................... 58
«Кояшны кызык иттем...» ................. 59
Күркә ........................................ 59
Кояш ......................................... 59
Алма ашарга кирәк ........................ 60
Тычкан да алданмаган .................... 60
Ур-ра, физкультура! ....................... 61
Бөрлегән утырттык ........................ 62
Имеш, мөгез чыга, ди ..................... 62
«Аждаһа» очырдым ........................ 63
Кыш та, җәй дә чаңгыда .................. 63
Алинә кунак ярата ......................... 64
Кояшыбыз тулып торсын .................. 64
Әтәч бирде кирәкне ........................ 64
Эш көлеп кенә тора ........................ 66
Көз ........................................... 67
Бал корты ................................... 67
«Әни» сүзе .................................. 67
Күрми калам йокыны ....................... 68

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного и младшего школьного возраста

**Музагит**
(***Ахметзянов*** *Музагит Загитович*)

## Хочу быть смелым

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Мөҗәһит**
(***Әхмәтҗанов*** *Мөҗәһит Заһит улы*)

## Батыр буласым килә

Мөхәррире *Э.Т.Кәлимуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Р.Н.Нуриева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.12.2010.
Форматы 84´100 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 7,2.
Тиражы 3000 д. Заказ О-1704.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.